**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# 2020 елда Казан шәһәрендә Бәйсез Дәүләтләр Берлеге илләренең I уеннарын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитетын төзү турында

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм җәмәгать берләшмәләренең 2020 елда Казан шәһәрендә Бәйсез Дәүләтләр Берлеге илләренең I уеннарын әзерләүдә һәм уздыруда үзара хезмәттәшлеген оештыру максатларында **карар бирәм:**

1. 2020 елда Казан шәһәрендә Бәйсез Дәүләтләр Берлеге илләренең I уеннарын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитетын төзергә.

2. 2020 елда Казан шәһәрендә Бәйсез Дәүләтләр Берлеге илләренең I уеннарын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты турындагы нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН • ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 14 май
№ ПУ-285

Татарстан Республикасы
Президентының
2020 елның «14» маендагы
ПУ-285 номерлы Указына
1 нче кушымта

**2020 елда Казан шәһәрендә Бәйсез Дәүләтләр Берлеге илләренең I уеннарын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты турындагы нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. 2020 елда Казан шәһәрендә Бәйсез Дәүләтләр Берлеге илләренең I уеннарын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты (алга таба – Республика оештыру комитеты, БДБ илләренең I уеннары) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм җәмәгать берләшмәләренең БДБ илләренең I уеннарын әзерләү һәм уздыруда үзара хезмәттәшлеген оештыру максатларында төзелгән коллегиаль орган булып тора.

1.2. Республика оештыру комитеты үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына һәм аның башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

II. Республика оештыру комитетының төп бурычлары

2.1. Республика оештыру комитетының төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

Казан шәһәрен БДБ илләренең I уеннарын уздыруга әзерләү буенча республика чаралар планын (алга таба – республика чаралар планы) формалаштыру буенча тәкъдимнәр эшләү;

Казан шәһәрен БДБ илләренең I уеннарын уздыруга әзерләү белән бәйле планнарны, программаларны һәм аерым чараларны гамәлгә ашыруның барышына анализ, республика чаралар планын үтәүгә һәм аны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелгән акчаның максатчан файдалануына контрольне тәэмин итү;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары (алга таба – федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары), Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары), оешмалар һәм

җәмәгать берләшмәләренең Республика оештыру комитеты тарафыннан кабул ителгән карарларны тормышка ашыру барышында үзара хезмәттәшлеген оештыру буенча тәкъдимнәр эшләү һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү;

республика чаралар планын үтәү белән бәйле бурычларны хәл иткәндә, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм җәмәгать берләшмәләренең үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү.

2.2. Республика оештыру комитеты үзенә йөкләнгән бурычларны хәл итү максатларында түбәндәгеләргә хокуклы:

законнар нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм җәмәгать берләшмәләреннән Республика комитеты компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча мәгълүмати материаллар соратып алырга;

Республика оештыру комитеты компетенциясенә караган мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән тәртиптә эш төркемнәре төзергә;

үз утырышларына билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм җәмәгать берләшмәләре җитәкчеләрен һәм аларның башка вәкилләрен, башка кызыксынган затларны чакырырга;

БДБ илләренең I уеннарын әзерләү һәм уздыру мәсьәләләре буенча киңәшмәләрдә, конференцияләрдә һәм семинарларда катнашу өчен үз вәкилләрен җибәрергә.

## III. Республика оештыру комитеты составы

3.1. Республика оештыру комитеты составы Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

3.2. Республика оештыру комитеты составына аның рәисе, рәис урынбасарлары, секретаре һәм Республика оештыру комитеты эшендә җәмәгать башлангычларында катнашучы башка әгъзалары керә.

3.3. Республика оештыру комитеты рәисе булып Татарстан Республикасы Президенты тора.

3.4. Республика оештыру комитеты рәисе:

Республика оештыру комитеты эшенә җитәкчелек итә;

урынбасарлары һәм Республика оештыру комитеты әгъзалары арасында бурычларны бүлеп бирә;

Республика оештыру комитеты эшчәнлеге планы нигезендә утырышларның көн тәртибен, аларны уздыру датасын, вакытын һәм урынын билгели һәм раслый;

үзе булмаган вакытка Республика оештыру комитеты рәисе вазыйфаларын башкаручы итеп үзенең урынбасарларының берсен билгели;

утырыш беркетмәләренә һәм Республика оештыру комитетының башка документларына кул куя.

3.5. Республика оештыру комитеты секретаре:

Республика оештыру комитеты утырышларында катнаша;

Республика оештыру комитеты әгъзаларына биш көннән дә соңга калмыйча, утырышны уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында хәбәр итә, утырышның көн тәртибен һәм аның материалларын җибәрә;

Республика оештыру комитеты утырышлары беркетмәләрен һәм башка документларын әзерләү өчен җавап бирә.

3.6. Республика оештыру комитеты әгъзалары:

Республика оештыру комитеты утырышында шәхсән катнаша;

Республика оештыру комитеты компетенциясендәге мәсьәләләр буенча тәкъдимнәрне фикер алышуга куя;

Республика оештыру комитеты карап тикшерә торган мәсьәләләр буенча материаллар белән таныша;

Республика оештыру комитеты карарларын әзерләү, үтәү, аларның үтәлешенә контрольлек итү буенча кирәкле чараларны башкара.

## IV. Республика оештыру комитеты утырышлары һәм карарлары

4.1. Республика оештыру комитеты утырышлары ким дигәндә ике айга бер тапкыр уздырыла. Утырышлар графигы Республика оештыру комитеты рәисе тарафыннан раслана һәм Республика оештыру комитеты секретаре тарафыннан Республика оештыру комитеты әгъзаларына җиткерелә.

4.2. Кирәк булган очракта, Республика оештыру комитеты рәисе карары буенча Республика оештыру комитетының чираттан тыш утырышы уздырылырга мөмкин.

4.3. Республика оештыру комитеты утырышының көн тәртибе мәсьәләләре буенча материаллар Республика оештыру комитеты секретарена утырыш билгеләнгән датадан 15 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырылырга тиеш. Килгән материаллар нигезендә секретарь Республика оештыру комитеты утырышының көн тәртибе проектын әзерли һәм аны утырыш уздырыласы көнгә кадәр 12 эш көненнән дә соңга калмыйча, Республика оештыру комитеты рәисенә раслауга кертә.

4.4. Утырышның көн тәртибе Республика оештыру комитеты рәисе тарафыннан раслана. Утырышның көн тәртибе расланганнан соң аңа үзгәрешләр кертү бары тик Республика оештыру комитеты рәисе карары белән генә мөмкин була. Бу очракта Республика оештыру комитеты секретаре Республика оештыру комитеты күрсәтмәсе буенча утырышның көн тәртибенә үзгәрешләр кертә һәм бу хакта Республика оештыру комитеты әгъзаларына хәбәр итә.

4.5. Республика оештыру комитеты утырышларын рәис яисә аның кушуы буенча рәис урынбасарларының берсе алып бара.

4.6. Республика оештыру комитеты әгъзалары утырышларда шәхсән катнаша. Республика оештыру комитеты әгъзасы утырышта катнашмаган очракта, карап тикшерелә торган мәсьәләләр турында фикерен язма рәвештә тапшырырга хокуклы.

4.7. Республика оештыру комитеты утырышлары, әгәр анда әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, гамәлгә хокуклы санала. Әгәр

утырышта катнашучы әгъзаларының ким дигәндә яртысы Республика оештыру комитеты карарын хуплап тавыш бирсә, ул кабул ителгән дип санала. Республика оештыру комитеты утырышларында көн тәртибе мәсьәләләрен карап тикшерү һәм тавыш бирү нәтиҗәләре буенча беркетмә белән рәсмиләштерелә торган карарлар кабул ителә. Республика оештыру комитеты утырышы беркетмәсенә утырышта рәислек итүче кул куя.

4.8. Республика оештыру комитеты кабул итә торган карарлар агымдагы эшчәнлекләрен башкарганда аларга нигезләнеп эш итү өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмалар һәм җәмәгать берләшмәләренә, башка кызыксынган затларга җибәрелә.

## V. Республика оештыру комитеты эшчәнлеген тәэмин итү

5.1. Республика оештыру комитеты эшчәнлеген оештыру ягыннан һәм мәгълүмати яктан тәэмин итүне Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының тиешле структур бүлекчәләре башкара.

---

Татарстан Республикасы
Президентының
2020 елның «14» маендагы
ПУ-285 номерлы Указына
2 нче кушымта

**2020 елда Казан шәһәрендә Бәйсез Дәүләтләр Берлеге илләренең I уеннарын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты составы**

| | |
|---|---|
| Миңнеханов Рөстәм Нургали улы | Татарстан Республикасы Президенты, Республика оештыру комитеты рәисе |
| Фазлыева Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Республика оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Леонов Владимир Александрович | Татарстан Республикасы спорт министры, Республика оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Метшин Илсур Рәис улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы, Республика оештыру комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Денисов Максим Сергеевич | «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» автоном коммерциячел булмаган оешмасы генераль директоры, Республика оештыру комитеты секретаре (килешү буенча) |
| Әгълиуллин Фәнил Әнвәр улы | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры |
| Афанасьев Андрей Игоревич | Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Саратов һәм Самара өлкәләре буенча Чик буе идарәсе «Идел буе» чик буе контроль отрядының «Казан-аэропорт» контроль-үткәрү пункты башлыгы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Әюпова<br>Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |
| Бариев<br>Марат Мансур улы | Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты (килешү буенча) |
| Богомолов<br>Станислав Юрьевич | Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Транспортта Казан линия идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Вахитов<br>Радик Рафикъ улы | Россия Федерациясе Чит илләр эшләре министрлыгының Казан шәһәрендәге вәкиле (килешү буенча) |
| Габдерәшитов<br>Булат Рәшит улы | Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт протоколы идарәсе башлыгы |
| Гафуров<br>Илшат Рәфкать улы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Громушкин<br>Петр Николаевич | Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгының беренче урынбасары (килешү буенча) |
| Гомәров<br>Рөстәм Фәрит улы | Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Иванов<br>Сергей Евгеньевич | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе |
| Кальков<br>Геннадий Алексеевич | Федераль таможня хезмәтенең Идел буе таможня идарәсе Татарстан таможнясы башлыгы вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Маврина<br>Лилия Николаевна | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре (килешү буенча) |
| Обвинцев<br>Алексей Анатольевич | Россия Федерациясе Спорт министрлыгының Мәгариф, фән һәм халыкара мөнәсәбәтләр департаменты директоры (килешү буенча) |
| Патяшина<br>Марина Александровна | Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Рәхимов<br>Илнур Сөләйман улы | Татарстан Республикасының «Универсиада авылы» дәүләт автоном учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Романцов<br>Сергей Анатольевич | «Казан» халыкара аэропорты» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Садыйков<br>Марат Наил улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Сәлимгәрәев<br>Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Сафин<br>Ленар Ринат улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| Сергеев<br>Сергей Валентинович | Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе башлыгы урынбасары – күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Фәйзрахманов<br>Марат Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары – Татарстан Республикасының Казначылык департаменты директоры |

| | |
|---|---|
| Фәттахов<br>Дамир Илдус улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры |
| Хәйруллин<br>Айрат Ринат улы | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры |
| Хәнифов<br>Фәрит Мөдәррис улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры |
| Хохорин<br>Артём Валерьевич | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры (килешү буенча) |
| Шәйхетдинов<br>Хәлил Хәмит улы | Татарстан Республикасы спорт министрының беренче урынбасары |
| Шакирова<br>Гүзәл Рәис кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы |
| Шәрипов<br>Ирек Илдус улы | «Татарстанның Халыклар дуслыгы йорты» дәүләт бюджет учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Якубов<br>Йосыф Җиһанша улы | «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |